ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.10.2023г. Баулы шәһәре №187

2024 елда Баулы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә белем турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законнарына ярашлы, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында һәм муниципаль мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем алучы укучыларның түләүсез кайнар тукlануын оештыру буенча чаралар исемлеген раслау турында” 2020 елның 14 июлендәге 588 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Министралар Кабинетының 2023 елның 4 сентябрендәге 1066 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында бушлай кайнар аш белән тәэмин итү норматив чыгымнарны раслау турында һәм гомуми белем бирүче программалар буенча белем алган башлангыч белем бирү оешмаларында укучыларны бушлай кайнар аш белән тәэмин итү” карары белән, Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының 2023 елның 7 сентябрендәге 1099 номерлы “2024-2026 елларга айлык акчалата түләүләр һәм башка төр түләүләр турында”, муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулы туклану белән тәэмин итү, сәламәт туклануны оештыру өлешендә «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларның туклануын оештыру» турында СанПиН 2.4.5.2409-08 таләпләрен үтәү, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУсын, Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының, Баулы муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм района гомуми белем бирү оешмаларында кайнар туклануны ташламалы шартларда оештыруны гамәлгә ашыручы предприятиеләргә субвенцияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. 2024 елның 1 гыйнварыннан Баулы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укыган вакытта бер укучыга көненә кайнар туклану бәясе күләмен билгеләргә:

бюджет хисабына:

- шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныфларда укучыларга – 66 сум 76 тиен;

- 5-11 сыйныфларда укучылар өчен – 9 сум 20 тиен;

ата-аналар взносы хисабына:

- 5-11 сыйныфларда укучылар өчен:

шәһәрдә: иртәнге аш – 15 сум 75 тиен, төшке аш – 51 сум 03 тиен, озайтылган көн төркеменә – 21 сум 00 тиен;

авылда: иртәнге аш – 15 сум 75 тиен, төшке аш – 39 сум 69 тиен.

3. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге” МКУ начальнигы Д.З.Ганиевага Бердәм дәүләт социаль тәэмин итү мәгълүмат системасын (ЕГИССО) кулланып, социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында мәгълүмат юнәлешен тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров